ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ СЭФЭР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423748, Иске Сэфэр авылы, М.Вахитов
ур., 16 нчы йорт. Тел.5-60-43

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОСАФАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423748, село Старое Сафарово,
ул. М.Вахитова ,дом 16 , Тел. 5-60-43

КАРАР
05.06.2019 ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№12

2019 елгы су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге ачык сулыкларда коенуны тыю турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының "Иске Сәфәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 03.06.2019 ел, №ПР-125 санлы карары белән, Иске Сәфәр авыл җирлеге территориясендә пляжлар һәм суда массакүләм ял итү урыннары булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге Башкарма комитеты, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елгы су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге ачык сулыкларда коенуны тыярга.
2. Су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда коенуны тыю турында халык белән аңлату эшләре һәм балаларны махсус контрольдә тоту кирәклеге турында белешмәлекләр өләшеп аңлату эшләре алып барырга;
3. Балаларны караучысыз тоту һәм өлкән кешеләр тарафыннан контрольдә тоту рөхсәт ителгән гаиләләрне аерым контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән шәхси профилактик эш алып барырга, ата-аналарга кул куйдырып коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга;
4. Ачык сулыкларда су коенуны тыю турында аншлаглар урнаштырырга;
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Иске Сәфәр авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.
6. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Сәфәр авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

Г.З.Сайфутдинова